ВӘГАЗЬ
Шәүвәл аеның фазыйләте
→ 6 БИТ

ВАКЫЙГА
Казанда XI Республикакүләм ифтар узды
→ 8 БИТ

ӘДӘП-ӘХЛАК
Мөэминнәрнең иң хәерлесе
→ 10 БИТ

ТӘРБИЯ
Гомерлек яр сайлау
→ 13 БИТ



**АПРЕЛЬ, 2023**
№ 04 (333)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

РАМАЗАН-ШӘҮВӘЛ, 1444


# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



Фото: shutterstock.com

**Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәү Рамазан ае уразасын тотып, соңрак шәүвәл аенда да алты көн ураза тотса, бер ел ураза тоткан кебек булыр», – дип әйткән. Бу сүз Рамазан ае уразаларын тотып, шәүвәл ае кергәннән соң, аның көннәрендә ураза тотучыга күпләп әҗер-саваплар биреләчәк, дигәнне аңлата, ягъни бу алты көн алдыннан Рамазан ае уразаларын тоту кирәк…**


ДӘВАМЫ → 6 НЧЫ БИТТӘ


ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (333) апрель, 2023 | Рамазан-шәүвәл, 1444

# ТАТАРСТАНДА 2023 ЕЛДА ХАҖГА БАРУ ӨЧЕН ГАРИЗАЛАР КАБУЛ ИТЕЛӘ




Фото: dumrt.ru

**Татарстанның «ТР МДН Хаҗ» рәсми хаҗ операторы 2023 елда хаҗ кылу өчен гаризалар кабул итә. Мәккә һәм Мәдинәнең изге урыннарында гыйбадәтләр сезоны якынча 8 июньнән алып 20 июльгә кадәр дәвам итәчәк. Быел хаҗга квоталар төбәкләрнең ихтыяҗларыннан чыгып бүлеп бирелә, Россия өчен квоталарның гомуми саны исә пандемиягә кадәрге күләмгә җитте – 25 000 урын. Моннан тыш, хаҗилар өчен дөньядагы санитар-эпидемиологик вәзгыятьтән чыгып кертелгән яшь белән бәйле барлык чикләүләр бетерелде.**

Татарстанда хаҗ калу өчен 4 программа эшләнде. Алар – 360 мең сумнан алып, 962 000 сумга кадәр. Бәяләр кунакханәнең дәрәҗәсе һәм Әл-Харам мәчетенең ераклыгына, сәфәрнең озынлыгына, маршрутның төренә (самолет белән яки самолет+автобус), тукланууга, юлламага корбанның һәм башка хезмәтләрнең кертелүенә карап билгеләнә. Ләкин нинди бәядән булуга карамастан, барлык юлламалар да үз эченә юл һәм трансфер чыгымнарын, Мәккә һәм Мәдинәдә яшәүне, Гарәфәт һәм Минада тору һәм туклануны, медицина хезмәтен, гарәп, татар һәм рус телле, шәригать белемле имамның – төркем җитәкчесенең озатып йөрүен, Зәм-зәм суын һәм хаҗи комплектын күздә тота. Хаҗи комплектына кирәкле әдәбият һәм букча керә.

«ТР МДН Хаҗ» гомрә һәм хаҗны оештыру буенча күпьеллык тәҗрибәгә ия һәм гыйбадәтне мөмкин кадәр уңайлы шартларда хәнәфи мәзһәбе буенча дөрес рәвештә башкаруны гарантияли. Моның өчен сәфәр алдыннан Нәзарәт белгечләре булачак хаҗиларга онлайн һәм офлайн рәвештә дәресләр бирә: аларга хаҗның тәртипләре, чит илдә, кунакханәдә, җәмәгать урыннарында, мәчеттә, экскурсияләрдә үзеңне тоту кагыйдәләре һ.б. аңлатыла. Аралашу Zoom, WhatsApp һәм Telegram-да бара.

Хаҗга гариза бирү яки урынны алып калу өчен **+7 843-21-21-300**, **+7-800-555-92-10** телефоннарына шалтыратырга мөмкин. Шулай ук сорауларны WhatsApp һәм Telegram аша **+7-966-240-53-96** һәм **+7-965-589-82-30** телефоннарына ирештерә аласыз.

Турлар Казаннан һәм Мәскәүдән түбәндәге программалар буенча оештырыла:

- ✔ **«Эконом комби»** – 360 000 сумнан башлап.
- ✔ **«Эконом авиа»** – 400 000 сумнан башлап.
- ✔ **«Стандарт»** – 464 000 сумнан башлап.
- ✔ **«ВИП»** – 962 800 сум* (*әлеге бәягә кунакханәдә 4 кешелек номер да керә).

## 1. «ЭКОНОМ – КОМБИ» КАЗАННАН ҺӘМ МӘСКӘҮДӘН:

- ✔ Сәфәрнең озынлыгы – 25-35 көн (шул исәптән Мәдинәдә 3 көн);
- ✔ Маршрут төре – самолет+автобус;
- ✔ Мәккәдә уңайлы җирдә урнашкан хаҗилар йортында тору (2 тапкыр туклану кертелгән*);
- ✔ Мәдинәдә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетеннән 600 метрдан да артмаган ераклыктагы кунакханәдә тору;
- ✔ 4-6 кешелек номерда тору;
- ✔ Дини белемле, гарәп телендә иркен аралашучы тәҗрибәле җитәкчеләрнең озатып йөрүе;

- ✔ Сәфәргә чыкканчы хаҗ гыйбадәтләренә өйрәтү, сәфәр барышында вәгазьләр һәм дәресләр тыңлау;
- ✔ Тәүлек буе медицина хезмәте (медпункт – кунакханәдә, 24/7);
- ✔ Согуд Гарәбстаны Корольлеге визасын һәм башка документларны әзерләү;
- ✔ Мина, Гарәфәт, Мөздәлифәдә чатырлы лагерьдә яшәү;
- ✔ Бүләккә 5 л Зәм-зәм суы;
- ✔ Хаҗи комплекты: бейдж, кирәкле әдәбият, сумка (рюкзак).

### 2. «ЭКОНОМ АВИА» КАЗАННАН ҺӘМ МӘСКӘҮДӘН:

- ✔ Сәфәрнең озынлыгы – 25-35 көн (шул исәптән Мәдинәдә 3 көн);
- ✔ Самолетлы маршрут;
- ✔ Мәккәдә уңайлы җирдә урнашкан хаҗилар йортында тору (2 тапкыр туклану кертелгән*);
- ✔ Мәдинәдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетеннән 600 метрдан да артмаган ераклыктагы кунакханәдә тору;
- ✔ 4-6 кешелек номерда тору;
- ✔ Дини белемле, гарәп телендә иркен аралашучы тәҗрибәле җитәкчеләрнең озатып йөрүе;
- ✔ Сәфәргә чыкканчы хаҗ гыйбадәтләренә өйрәтү, сәфәр барышында вәгазьләр һәм дәресләр тыңлау;
- ✔ Тәүлек буе медицина хезмәте (медпункт – кунакханәдә, 24/7);
- ✔ Согуд Гарәбстаны Корольлеге визасын һәм башка документларны әзерләү;
- ✔ Мина, Гарәфәт, Мөздәлифәдә чатырлы лагерьдә яшәү;
- ✔ Мина һәм Гарәфәттә туклану;
- ✔ Бүләккә 5 л Зәм-зәм суы;
- ✔ Хаҗи комплекты: бейдж, кирәкле әдәбият, сумка (рюкзак).

### 3. «СТАНДАРТ» КАЗАННАН ҺӘМ МӘСКӘҮДӘН:

- ✔ Сәфәрнең озынлыгы – 14-25 көн (шул исәптән Мәдинәдә 3 көн);
- ✔ Самолетлы маршрут;
- ✔ Әл-Харам мәчетеннән 1,5-2 чакрымнан да артмаган ераклыктагы кунакханәдә урнашу (Әл-Харам мәчетенә кунакханәдән трансфер каралган);
- ✔ Мәдинәдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетеннән 350 метрдан да артмаган ераклыктагы кунакханәдә урнашу;
- ✔ 3-5 кешелек номерда тору;
- ✔ Дини белемле, гарәп телендә иркен аралашучы тәҗрибәле җитәкчеләрнең озатып йөрүе;
- ✔ Сәфәргә чыкканчы хаҗ гыйбадәтләренә өйрәтү, сәфәр барышында вәгазьләр һәм дәресләр тыңлау;
- ✔ Тәүлек буе медицина хезмәте (медпункт – кунакханәдә, 24/7);
- ✔ Согуд Гарәбстаны Корольлеге визасын һәм башка документларны әзерләү;
- ✔ Мина, Гарәфәттә, Мөздәлифәдә чатырлы лагерьдә яшәү;
- ✔ Мәккә һәм Мәдинә кунакханәләрендә туклану (2 тапкыр, төрек ашлары);
- ✔ Мина һәм Гарәфәттә туклану;
- ✔ Корбан чалу чыгымнары бәягә кертелгән;
- ✔ Бүләккә 5 л Зәм-зәм суы;
- ✔ Хаҗи комплекты: бейдж, кирәкле әдәбият, сумка (рюкзак).

### 4. V.I.P.

- ✔ Сәфәрнең озынлыгы – 12-14 көн (шул исәптән Мәдинәдә 3 көн);
- ✔ Самолетлы маршрут;
- ✔ Мәккәдә Әл-Харам мәчете җирлегендә 5* кунакханәдә (Fairmont яки аналог) урнашу;
- ✔ Мәдинәдә 5* кунакханәдә (Pullman Zamzam Madina* яки аналог) урнашу;
- ✔ 2-4 кешелек номерларда тору* (*соңгы бәя номерда яшәгән кеше санына карап билгеләнә);
- ✔ Аэропорттан кунакханәгә һәм кире, шулай ук шәһәрләр арасында һәм экскурсияләр вакытында трансфер (VIP автобуслары);
- ✔ Дини белемле, гарәп телендә иркен аралашучы тәҗрибәле җитәкчеләрнең озатып йөрүе;
- ✔ Сәфәргә чыкканчы хаҗ гыйбадәтләренә өйрәтү, сәфәр барышында вәгазьләр һәм дәресләр тыңлау;
- ✔ Согуд Гарәбстаны Корольлеге визасын һәм башка документларны әзерләү;
- ✔ Мина, Гарәфәт, Мөздәлифәдә чатырлы лагерьдә яшәү;
- ✔ Мәккә һәм Мәдинә кунакханәләрендә туклану (швед өстәле);
- ✔ Мина һәм Гарәфәттә туклану;
- ✔ Корбан чалу чыгымнары бәягә кертелгән;
- ✔ Хаҗи комплекты: ихрам, бейдж, кирәкле әдәбият, сумка (рюкзак);
- ✔ Бүләккә 5 л Зәм-зәм суы;
- ✔ Тәүлек буе медицина хезмәте.

**dumrt.ru** сайтыннан



Фото: dumrt.ru

# Рамазанның соңгы көнендә «Зәкят» фонды Казанда яңа аллеялар утыртты

**Рамазан аеның соңгы 29 нчы көнендә Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм «Гаилә» мәчете тирәләрендә агачлар утыртты.**

Яңа аллеяларда хәзер алмагач, груша, слива үсә. Үсентеләр Фондның үз акчасына садакаи-җәрия буларак сатып алынды. Садакаи-җәрия дип, мәчет-мәдрәсәләр, мәктәпләр, хастаханәләр төзетү, урманнар утырту, юл-күперләр салу, чишмә-коелар казу, Коръән бастыру һ.б. кешеләргә гомер буе файда китерә торган гамәлләр кылуга әйтәләр. Садакаи-җәриянең әҗер-савабы кеше үзе үлгәннән соң да тукталмый.

Барлыгы 30 төп Ураза гаете алдыннан фонд, мәдрәсә һәм мәчет хезмәткәрләре, шәкертләр һәм мәхәллә халкы тарафыннан утыртып куелды. Агачлар дөрес формада үссен һәм бер-берсеннән тиешенчә аралык калсын өчен урыннар билгеләнде, җир әзерләнде. Аннары хезмәткәрләр чокыр казыды, туфракны йомшартып су һәм ашлама сипте, тигез итеп җиләк-җимеш агачларын утыртты.

Агачлар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе каршындагы мәйданда һәм ишегалдында, «Гаилә» мәчетендә җиләк-җимеш культуралары яңа төзелә торган Ислам үзәге янәшәсендә – мәчет белән «Мирас» стадионы арасындагы буш урында утыртылды.

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (333) апрель, 2023 | Рамазан-шәүвәл, 1444

# ИМАН ҺӘМ СУГЫШ

## (ҖИҢҮНЕҢ 78 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНА)

**Кеше өчен иң кадерле төшенчә – ул гомер. Ул Аллаһы Тәгаләдән бер генә тапкыр бирелә. Бу хакыйкатьне белә торып, Николай Островскийны кабатлап шуны әйтәм: ул гомерне «максатсыз үткән еллар өчен үкенмәслек итеп» үткәрергә кирәк.**

Яшьлек елларында да һәм үзенең туксанга җитеп килгән, аннан да арткан яшендә дә һәрберебез: «Минем бөтен тормышым аңлы рәвештә дөньядагы иң күркәм эшкә – бүгенге көндә авырлык кичерүче кешеләргә ярдәм итү өчен көрәшкә багышланды», – дип әйтерлек булсын.

Бәлага дучар булган бер кешегә, кешеләр төркеменә, җәмәгатьчелеккә, илгә, дәүләткә ярдәм итү – ул төп нигез, барлык алга киткән диннәрнең: мөселман, насара, православия, католик, яһүди, протестант һәм Көнчыгыш халыклары диннәренең иң мөһим мәсьәләсе.

Һәр кешегә, һәр гаиләгә авыр булган. 1941 елның 22 нче июнендә фашистлар Аурупаның Үзәк һәм Көнбатыш илләрен яулап алып, буйсындырылган илләрнең матди һәм рухи байлыкларын үзенеке итеп, илебезгә килеп кергәндә ни дәрәҗәдә кыен булган!

Библиянең беренче чыганакларында һәм Коръәни Кәримнең аятьләрендә аңлатылган илаһи күрсәтмәләрне истә тотып, рус, татар, белорус, украин милләте халыклары, Кавказ, Урта Азия, Себер, Ерак Көнчыгыш республикалары халыклары зур дошман – фашизм белән көрәштә берләште.

Шайтан белән көрәштә безне гомумкыйммәтләр берләштерә иде.

Берләштерү башлангычының нигезенә Аллаһы Тәгалә мөһим төшенчә – «толерантлык» – ватандашларыбызның үзенчәлекләренә, аларның дөньяга карашларына, фикер йөртүләренә, дөньяны күзаллауларына һәм, әлбәттә инде, дин тотуларына карата хөрмәт салган иде. Дуслык – бердәмлек, уңыш, җиңү ачкычы.

Моннан чыгып, фашистлар 1939 елда башлап җибәргән сугышны, сигез ел элек Украина шайтаннары тарафыннан башланган сугышны кяфер Иблис гамәле дип әйтеп була.



Фото: dumrt.ru

Диннәр арасында Аллаһы Бер, фәрештәләр һәм пәйгамбәрләр бер, Изге Китаплар төрле чорлар һәм барлык халыклар өчен Бер.

– татар кешесе Габдрахман өчен аерым илаһ юк;

– рус кешесе Иван өчен аерым илаһ юк;

– яһүд кешесе Аврам өчен аерым Яхфә юк.

Без дини йолаларны үтәүдә аерылабыз, әмма бусагада фашист-кяфер торганда иман китерүчеләргә аермалык эзләү – гөнаһ. Шулай булгач, фашист-кяферне җиңү өчен, төрле дин тотучыларны берләштерә торган илаһи гыйлемнәрнең нигезен, кешелек яшәеше нокталарын бертуктаусыз эзләргә кирәк.

Менә ни өчен сугыш башында Советлар Союзындагы барлык дини оешмалар совет дәүләтенә лояль мөнәсәбәттә булу позициясенә күчкән, бу сугышның беренче көннәреннән үк патриотик караш формалашуга сәбәп булган. 1941 елда, рус-православия чиркәве башлыгы митрополит Сергий һәм шулай ук Советлар Союзы мөселманнары Үзәк Дини нәзарәте, патриотик рухтагы хат белән, Аллаһыга ышанучыларга мөрәҗәгать итте.

СССРның дини оешмалары арасыннан беренче булып Үзәкләшкән дини оешма – мөселманнар Дини нәзарәте, мөфти Габдрахман Расүлев җитәкчелегендә алман фашистларының яулап алулары хакында иман китерүчеләргә патриотик рухтагы мөрәҗәгатьне бастырып чыгарды.

Дингә ышанучылар исеменнән мөфти болай диде: «Фашистлар Германиясенә һәм аның ялчыларына каршы барган бу Бөек Ватан сугышында үзегезнең хаклы булуыгызны исбатлап, бөтен дөнья каршында үз Ватаныгызга тугры булуыгызны күрсәтегез, Кызыл Армиянең җиңүе өчен мәчетләрдә дога кылыгыз. Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы Тәгаләгә дошманны тизрәк җиңү, барлык кешелекнең, мөселман дөньясының залимнәрдән – фашистлардан котылу хакында дога кылып сорагыз».

Мин үзебезнең Балтач районы Чутай авылы имамы Нурзадә хәзрәт Нәсыйхне – дөньяга карашы буенча мөселман җәдиден яхшы хәтерлим. Ул Изге Китаптан һәм пәйгамбәребез Мөхәммәднең хәдисләреннән чыгып, фронтка китүче авылдашларны кяфер-фашистлар белән көчләрен һәм гомерләрен кызганмыйча яу кырында сугышырга чакырган иде. Ул: «Яу кырына баручы сугышчыга ярдәм итү сугышта залим белән көрәшүгә тиң», – дип әйтә иде.

Дини оешмалар илнең оборонасы фондына акчалар җыюны оештырып, үз өлешләрен кертте.

ТР Рәисе Р.Н. Миңнеханов: «Бердәм халык, бердәм ил булып, без сугыш авырлыкларын һәм сынауларын уздык. Сугыш чоры буыны вәкилләренең барлык гамәлләре һәм фикерләре бер генә максатка корылган иде – түзем булу, исән калу һәм җиңү. Бөек Җиңүнең сугышчылары үзләренең тарихи йөкләмәләрен тиешле дәрәҗәдә башкарды, илгә һәм бөтен дөньяга нацизм коллыгыннан азатлык алып килде», – дип әйтә.

«Язмыш безнең Ватанны гаять җаваплы тарихи хәлләргә куйды. Россия шул ук вакытта насара һәм Ислам дине иле. Бу аңа махсус вазифалар йөкли. Бер яктан, Россия күпконфессияле держава һәм үз халкы арасындагы күршеләрчә мөнәсәбәтләрне сакларга, икенче яктан, ул бу күркәм мөнәсәбәтләрне дөньяга тапшырырга тиеш. Татарстан моңа әзер, яңа чорда хасил булган тәҗрибә дин ирегә белән тулы».

Шул ук вакытта Россиянең православия вәкилләре һәм мөселманнар шуны онытмаска тиеш: бүген, россиялеләрнең әкрен, әмма мәҗбүри рәвештә матди халәтләренең яхшыруы шартларында, кешеләрнең рухи дөньясы, әйтерсең лә, кирегә бара торган арифметик прогрессия сыман, түбән төшә. Шуңа да әхлакны тәрбияләү проблемалары, башка вакытка караганда да, иң актуаль, җаваплы бурыч булып тора. Һәм бу бурыч аерым һәрбер кеше өстенә, шулай ук мәктәп, җәмгыять өстенә тапшырыла.

Мисал китерик, әйтик, бүген «а» классында расписание буенча физика фәне бара. Тема – «электр тогы». Физика укытучысы балаларга электр тогының ябык үткәргечтә ирекле электроннарның тәртипле хәрәкәте булуын, бу хәрәкәтнең электр йөртү көче тәэсирендә башкарылуын аңлата. Димәк, электр тогының хәрәкәте тәртипкә салынган гамәл.

Ә «б» классында астрономия фәне укытучысы «галактика» темасы буенча дәрес бирә, Галәмдә миллиардтан артык галактика барлыгын, аларның һәрберсендә миллиардка якын йолдызлар, планеталар булуын аңлата. Аларның барысы да килешенгәнчә, үзләренең кучәрләре, траекторияләре, орбиталары әйләнәсендә хәрәкәт итә. Моның белән бергә аларның берсе дә икенчесенең юлын кисеп үтми. Димәк, Галәмдә галактикаларның, йолдызларның хәрәкәте тәртипкә салынган.

Ә нинди Көч аларны барлыкка китергән һәм ирекле электроннарның, галактикаларның, йолдызларның хәрәкәтләрен тәртипкә салган? Иван, синме? Юк! Габдрахман, синме? Юк! Император, синме? Юк! Синме, губернатор? Юк! Димәк, Халык кылучы бар. Галәмнәрнең Бөек Яратучысы бар! Аның исеме – Аллаһы Тәгалә! Ул Бердәнбер, Ул Галәмнәрнең Хуҗасы.

Җирдә һәм күкләрдә җәйга салынганлык, барлык диннәр һәм фәннәр: математика, биология, химия, география, механика, проза, медицина, компьютер технологиясе һәм башкалар Аллаһы Тәгалә тарафыннан тормышка ашырылган өзлексез яңартылуда тора.

Укытучының бурычы – бу тәртипкә салынган кануннарны диннәр һәм фәннәр бердәмлегендә табу,



Фото: tatarstan.roskazna.gov.ru

тану һәм дәрестә боларны укучыга аңлатып бирә алу.

Укытучының һәм укучының рухи дөньясы диндәге төзеклек һәм фәнни танып-белүнең төрле формаларын үзенә туплап, һәр дәрестә, темада толерантлык, дин ireген тану таләпләрен саклап алып барыла.

Сүз дин дәресен укыту хакында түгел, ә Яратучыга ышанучы һәм үз фәнен яхшы белүче укытучының дәрес азагында әлеге предметка һәм темага кагылышлы, беркем белән дә инкяр ителми торган Изге Китаплардагы дәлилләрне аңлату өчен, биш минут вакыт табуы хакында бара.

Православия, яһүди, мөселман диннәре нигезенең бөтендөнья фәннәре ачышлары белән уртаклыгын аңлаган һәм кабул иткән очракта гына кеше үз-үзен таныячак. Кеше үз-үзен танып, Яратучыны таный һәм аңлы рәвештә Яратучының әйткәннәрен үти башлый, күндәмлек, дин ирекен тану, өмет һәм ярату юлына баса.

**Харис Салих улы Салихов,**
«Хәтер» мәчете имам-хатыйбы
Бөек Ватан сугышы инвалид-ветераны,
Россия гуманитар фәннәр академиясенең
хөрмәтле әгъзасы һәм академик,
ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт
премиясе лауреаты

# ШӘҮВӘЛ АЕНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЕ

**Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Рамазан аеның бетүе белән шәүвәл ае башлана. Бу айда алты көн ураза тоткан кеше бер ел ураза тоткандай булыр. Аны дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көнне дә, шулай ук Рамазан бәйрәме узганнан соң да тотып була. Бу ураза казага калган ураза булып саналмый. Ураза гаетенең беренче көнендә бәйрәм итеп, соңыннан икенче көнендә уразага керергә мөмкин.**

Сахих булган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәү Рамазан ае уразасын тотып, соңрак шәүвәл аенда да алты көн ураза тотса, бер ел ураза тоткан кебек булыр», – дип әйткән.

Бу сүз Рамазан ае уразаларын тотып, шәүвәл ае кергәннән соң, аның көннәрендә ураза тотучыга күпләп әҗер-саваплар биреләчәк, дигәнне аңлата, ягъни бу алты көн алдыннан Рамазан ае уразаларын тоту кирәк.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә: «Бер изгелек кылучыга ун савап язылыр», – дигән. Рамазан аеның 30 көн уразасын унга тапкырлаганнан соң чыккан санга шәүвәл аеның алты көн уразасын унга тапкырлаганнан соң чыккан санны кушсак, 360 көн килеп чыга. Бу санга игътибар итсәк, Рамазан ае һәм шәүвәл аеның алты көн уразаларын тоткан очракта, тулы бер ел ураза тоткандай булабыз икән. Шуңа да Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм «бер ел ураза тоткан кебек булыр» дигән.

### ШӘҮВӘЛ АЕ УРАЗАСЫ – СӨННӘТ ГАМӘЛ

Шәүвәл ае уразасы фарыз да, вәҗиб тә түгел, ул сөннәт гамәл.

Болай дип риваять ителә: «Шәүвәл аеның алты көненең беренче көнендә тотылган уразаның савабы бик зур, кешенең 40 еллык гөнаһы булса да, Аллаһы Тәгалә аны гафу итәр. Һәм аңа 40 пәйгамбәрнең савабы язылыр». Бу да шәүвәл уразасына карата гына махсус шулай әйтелә.

Шәүвәл аеның икенче көнендә тотылган уразаның савабы өчен, 70 мәртәбә тырышлык күрсәтүгә чыккан кебек савап язылыр, бу кешегә кабер газабы булмас, диелә.

Кеше шәүвәл аеның өченче көнендә ураза тотса, йөз мең шәһитнең әҗер-савабы бирелер, аңа Кыямәт көненең авырлыгы җиңеләйтелер.

Дүртенче көнне ураза тотса, Аллаһы Тәгалә дөнья һәм Ахирәт теләкләреннән җитмеш теләген үтәр. Ифтар яисә сәхәр вакытында дога кылса, Аллаһы Тәгалә морадларын кабул итәр.

Бишенче көнне ураза тотучыга Аллаһы җәннәт киемнәрен кидерер һәм аның кылган догасын кабул кылыр.

Алтынчы көнне ураза тотучыга өммәтенең йөз мең кешесенә шәфәгать кылу хакы бирелер. Һәм аңа алтмыш мең ел гыйбадәт кылу савабын язар. Үлгәч, каберенә һәркөнне йөз мең фәрештә зиярат кылырга киләр. Һәм Кыямәт көнендә кадәр гамәл дәфтәрләре ябылмас. Шул алты көн шәүвәл уразасын тотып, ул елны вафат булса, шәһит дәрәҗәсенә ирешер.

### «ЙӨЗ МЕҢ ДӨЯ ЧАЛУДАН ДА ФАЗЫЙЛӘТЛЕРӘК...»

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләрен риваять иткән: «Шәүвәл ае уразасының алты көнен тотучыны Аллаһы Тәгалә җәһәннәм чылбырларыннан азат итәр».

Әбү Һөрайрадан килгән риваятьтә болай диелгән: «Берәү шәүвәл аеның алты көн уразасын рәттән тотса, алты йөз мең ел гыйбадәт кылып уздырса да, шулкадәр әҗер-саваплар ала алмас иде. Бу аңа алты йөз мең дөя чалудан да фазыйләтлерәк булыр иде. Ул алты йөз мең колны азат иткән кебек әҗер-савапларга ирешер иде».

Алты көн шәүвәл ае уразасын тотучыга Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтенең бөтенесе кадәр савап язылыр һәм ул хәзрәти Габбас, хәзрәти Хәсән һәм хәзрәти Хөсәенгә күрше булыр, диелә. Ләкин шунысы мөһим: бу гамәлләр ихлас күңелдән башкарылырга тиеш.

Рамазан аеннан соң килә торган шәүвәл ае безнең өчен үзенә күрә бер җиңеллек булып тора, чөнки Рамазан ае уразаларыннан соң шәүвәл аенда да ураза тоту һәм аның өчен күпләп әҗер-саваплар бирелү – Аллаһының рәхмәте ул. Әмма без Рамазан ае үтте дә, димәк, гамәл-гыйбадәтләребезгә карата җиңел карарга тиеш дип, фикер йөртмик. Аллаһы Тәгалә биргән һәр ай, һәр көн безнең өчен мөмкинлек ул.

### КАЛГАН АЙЛАРДА ДА ГЫЙБАДӘТТӘ БУЛЫЙК!

Рамазанда кылган изге гамәлләребез, биргән садакаларыбыз, төнге намазларыбыз, озаклап кылган догаларыбыз, динебез Исламны өйрәнү, китаплар уку, вәгазьләр, нәсыйхәтләр тыңлау, Коръәни Кәримне уку Рамазаннан соң да, шәүвәл аеннан соң да дәвам итәргә тиеш. Әйе, кемгәдер һәр көнне көненә 20 бит Коръән уку авыр булырга мөмкин. Әмма икенче берәүгә көненә 20 бит Коръән уку кыен түгел һәм шул рәвешле ул ай саен Аллаһының Китабын хәтем кыла ала. Башка берәү өчен көненә 10 бит яки 5 бит укырга җиңел булырга мөмкин, әмма без һич булмаса, көненә 2-3 бит булса да укысак та – бу да хәерле гамәл булыр. Вакыт үткән саен Коръән уку тизлегебез артып, Аллаһының рәхмәте белән, битләр санын тагы да үстерербез.

Гамәл-гыйбадәтләребезне күпләп, даими рәвештә кылу гадәтен Рамазан, шәүвәл аенда гына башкарып калмыйк, ә калган айларда да гыйбадәттә булыйк, гыйбадәттә булу – Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән вазифасы ул. Раббыбыз:

> ***«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым»,*** – дип әйтә.
>
> *«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56*

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Изге гамәлләрне тиешле дәрәҗәдә, ихластан башкарыгыз. Һәм истә тотыгыз: сез җәннәткә Аллаһының рәхмәте белән генә керәчәксез. Шуны белегез: Аллаһы каршында иң сөекле гамәл – зур булмаса да, даими кылынган гамәл», – дигән (имам Әл-Бохари).

Раббыбыз кылган изге гамәлләребездән риза булса иде.

**Ирек хәзрәт Җиһаншин,**
Габдрәхим Утыз Имәни исемендәге
«Ал Таң» мәчете имам-хатыйбы

# Суга чумып чыгу тәһарәтне алыштырамы?


Фото: unsplash.com

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Хәнәфи мәзһәбендә суга чумып чыгу тәһарәтне алыштыра, диләр. Бу дөресме? Мондый тәһарәт белән намаз уку ярыймы?**

**ҖАВАП:** Вә галәйкүм әссәләм! Әйе, ният тәһарәтнең шарты түгел. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

***«Ий, иман китерүчеләр! Намазга басарга әзерләнгән чагыгызда*** *[әгәр тәһарәтле түгелсез икән]* ***йөзләрегезне һәм терсәкләрегезгә кадәр*** *[аларны кертеп]* ***кулларыгызны юыгыз, башларыгызны мәсех кылыгыз, аякларыгызны да тубыкларга кадәр*** *[аларны кертеп юыгыз]».*

*«Әл-Маидә / Табын», 5:6*

Күргәнегезчә, аятьтә юылырга тиешле барлык әгъзалар саналса да, ният турында сүз әйтелмәгән. Әмма тәһарәт алырга ният кылу, билгеле тәртиптә тән әгъзаларын юу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте булуын онытмаска кирәк. Кайбер мөселманнар сөннәт һәм башкарылуы мәҗбүри булмаган гамәлләрне бер рәткә куя, бу дөрес түгел. Сөннәтне башкармыйча, гел калдырып килгән кеше гөнаһлы була. Аллаһы безне бу ялгышулардан сакласын.

Сезнең сорауга килгәндә дә шул ук хәл: сезнең тәһарәтегез һәм шул тәһарәт белән укылган намазыгыз дөрес, әмма сөннәт турында да онытмагыз.

Ә Аллаһы яхшырак белүче!

# Тәһарәт догалары

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Тәһарәт алганда аерым догалар укырга кирәк икән, ә мин белми идем. Минем тәһарәтем һәм намазым дөрес булганмы, кабул ителгәнме икән? Мине тәһарәт алырга өйрәткәндә бу турыда әйтүче булмады.**

**ҖАВАП:** Вә галәйкүм әссәләм! Чыннан да, кайбер чыганакларда тәһарәт алганда һәр әгъзаны юганда аерым дога, зикерләр әйтү турында хәбәр ителә. Мәсәлән, имам Ән-Нәвавинең «Әл-Әзкәр» китабы – шундый чыганакларның берсе. Әмма Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәһарәт алганда укылган догалары хакында төгәл мәгълүматлар юк, шунлыктан тәһарәт алганда дога яисә зикер әйтү шарт булып тормый.

Безгә бары бер генә мәгълүмат билгеле, ул да булса Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәһарәт алып бетергәч әйтелгән догасы:

أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ
لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ
اَللَّهُمَّ اجْعَلْنِي مِنَ التَّوَّابِينَ وَ اجْعَلْنِي مِنَ
الْمُتَطَهِّرِينَ

**Укылышы:** Әшһәдү әл-ләә иләәһә илләл-лааһү вәхдәһү ләә шарикә ләһ вә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһ. Аллааһүммәҗ-гальнии минәт-тәвәәбиинә вәҗ-гальнии минәл-мүтәтаһһириин.

**Мәгънәсе:** «Шәһадәт бирәм: Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы зат (илаһ) юк. Янә шәһадәт бирәм: тәхкыйк, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм – Аллаһы Тәгаләнең колы һәм бәндәләргә шәригать хөкемнәрен ирештерер өчен җибәрелгән Расүле. Мине чистарынучылар һәм тәүбә итүчеләрдән кыл» (Тирмизи, Таһәра/41).

Сезнең очракта, башка шартларын дөрес үтәгән булсагыз, тәһарәтегез һәм намазларыгыз дөрес санала.

Ә Аллаһы яхшырак белүче!

**dumrt.ru**
сайтыннан алынды

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (333) апрель, 2023 | Рамазан-шәүвәл, 1444






# КАЗАНДА XI РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ИФТАР УЗДЫ

**Рамазан аеның 25 нче көнендә (15 нче апрель кичендә) Казанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында XI Республикакүләм ифтар үтте. Бу юлы Татарстандагы иң зур авыз ачу мәҗлесе Рамазан аеның соңгы ункөнлегенә – гыйбадәт кылуда аеруча зур тырышлык күрсәтү вакытына туры килүе белән үзенчәлекле булды.**

Республикакүләм ифтарны Татарстан мөфтияте, «Ак Барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристик комплексы «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында оештырды. Анда республиканың төрле почмакларыннан 10,5 мең кеше җыелды. Алар арасында мохтаҗлар һәм азкеремлеләр, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, эшмәкәрләр, төрле төбәкләрдән килгән кунаклар һәм рәсми затлар бар иде. Ифтарга Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондыннан 200 мохтаҗ да килде.

Казанлылар өчен «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенә барып кайту шәһәр яны поездлары белән махсус бушлай рейс ярдәмендә тормышка ашырылды.

Традицион рәвештә авыз ачу мәҗлесенә килүчеләрнең сөенечен Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов бүлеште. Мәҗлесне хөрмәтләп дипломатлар да килде – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Илчелегенең Россиядәге беренче сәркатибе, сәяси бүлек башлыгы Мөхәммәд Рәшид Әлмансури, Россиядә Катар илчесе урынбасары Абдулла Йосыф Әс-Сааи, Төркия Республикасының Казандагы генераль консулы Исмәт Эрикан, Иран Ислам Республикасының Казандагы генераль консуллыгы җитәкчесе вазифаларын вакытлыча башкаручы Мосуд Моллаи, Төрекмәнстанның Казандагы генераль консулы Гунч Гәрәев, Казахстанның Казандагы генераль консулы Ерлан Исхаков, Үзбәкстан Республикасының Казандагы генераль консулы Фәриддин Насриев.

Республикакүләм ифтар кунакларын каршы алу, җәмәгать белән намаз укуны оештыру, ризык тарату һәм өстәлләрне җыештыруда ярдәм итү өчен 16 яшь һәм аннан өлкәнрәк 600 волонтер хезмәт күрсәтте. Алар өстәлгә ризык һәм суларны тезү, ифтарга килүчеләргә су өләшү, стюардлар сыйфатында аэроэкспресстан кунакларны каршы алу, аларны намаз уку һәм авыз ачу урынына озату, ифтар тәмам булгач, өстәлләрне җыю өчен җаваплы булды. Ифтарга кадәр алар белән Татарстан мөфтие очрашып нәсыйхәтләрен бирде. Ул аларга куйган хезмәтләре өчен рәхмәтен белдерде, волонтерларның әлеге чарада зур эш башкаруларын һәм моның өчен бирелә торган саваплар турында сөйләп үтте.

XI Республикакүләм ифтарның иң якты мизгелләре – фоторепортажда.

**dumrt.ru** сайтыннан















Фотолар dumrt.ru сайтыннан алынды

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (333) апрель, 2023 | Рамазан-шәүвәл, 1444

# МӨЭМИННӘРНЕҢ ИҢ ХӘЕРЛЕСЕ


Фото: shutterstock.com

**Ислам диненең асылы – әдәп-әхлак. Әхлагы күркәм булган мөселман кешесе башкалар алдында үзенең матур мөгамәләсе белән хөрмәт хисләре генә уята. Башкача булган очракта ул башка кешеләрне дә үзеннән читкә этәрә.**

Кызганычка, мөселман кешесе әдәпсез, әхлаксыз булса, Ислам динендә булмаган кешеләрнең динебез хакында яхшы булмаган фикерләр туына сәбәпче була. Әйе, мөселман кешесе һәрьяклап камил була алмый. Әмма динебез пакь, камил, кимчелексез. Һәркем шуны аңласа иде. Шулай да, мөэмин-мөселман кешесенә Ислам диненең бер олуг вәкиле булып яшәү бәхете насыйп булган икән, ул үзенең әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәте белән Ислам диненең күркәмлеген, сафлыгын күрсәтә алырга тиеш.

Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хакыйкатьтә, мин холыкларны күркәм итәр өчен җибәрелдем», – дип әйткән. Бу сүзләр безнең өчен зур әһәмияткә ия булырга тиеш, чөнки Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм күркәм холыклы кешене мөэминнәрнең хәерлесе дип атаган. Бу сүзләргә дәлил булып, әлеге хәдис тора. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бервакыт мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында булганда аның янына әнсарлардан булган бер кеше килде һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне сәламләп: «Йә, Расүлуллаһ, мөэминнәрнең иң хәерлесе кем?» – дип сорады. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Холкы күркәм булганы», – дип әйтте.

Сүз дә юк, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әхлак үрнәге, кимчелекләрдән пакь булган гаҗәеп кеше иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында:

***«Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе»,*** – дип әйтә.

*«Әл-Каләм», 68:4*

## «НАЧАР СЫЙФАТЛАР ГАМӘЛЛӘРНЕ БОЗА»

Үзе югары әхлак иясе булган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә холкыбызны күркәм итү, әдәп-әхлаклы булуның мөһимлеген гел әйтеп торган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Дөреслектә, аш серкәсе балны бозган кебек, начар сыйфатлар да гамәлләрне боза», – дигән хәдисендә безгә уйланыр өчен җирлек бар.

Кызганычка, булган хата-кимчелекләребез безнең гамәлләрне бер дә бизәми. Бүген киң таралган гайбәт сөйләү, сүз йөртү, бер-берләреннән көнләшү сәбәпле кешеләр арасында үзара аңлашылмаучанлык, хәтта күралмау хисләре барлыкка килүен күзәтәбез. Бу гамәлләр мөселманнар арасында да киң таралган булуы күңелне төшерә торган хәл. Әдәп-әхлак булмаганга күрә, бер-берләребезне хөрмәт итү, олыларны олы, кечеләрне кече итеп карый алмау очраклары да күп. Бу да олы бер кимчелектер.

Олы кимчелекләребезнең берсе – бер-берләребез хакында яхшы фикердә булырга теләмәү, бераз хатабыз булса, аны олы итеп күрү, «күпертү», кардәшебез хакында начар уйда булу. Бу гамәлнең гаеп эш булуы хакында Коръәндә болай диелгән:

***«Ий иман китерүчеләр! Фаразларның бик күбеннән сак булыгыз, чөнки, һичшиксез, кайбер фаразлар – гөнаһ. Янә*** *[бер-берегездән]* ***гаеп эзләмәгез, берәүләрегез икенчеләрегезнең гайбәтен сатмасын».***

*«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:12*

Моннан тыш, холкы начар булучы кешенең үзенә күп авырлык китерүен исәпкә алырга кирәк. Әбү Һөрайрадан тапшырылган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Холкы начар булучы кеше үз-үзен газапка тарткан», – дип әйткән. Ничек була икән соң бу, диярбез. Уйлап карыйк әле. Әйтик, холкы начар булучы кеше кемгә дә булса ачуланып йөреп, борчуга төшә, күңел тынычлыгын югалта. Шул сәбәпле саулыгына зыян сала. Юкка гына бәхетнең күңел тынычлыгы дигән мөһим төшенчәдә булуын әйтмиләр. Холкы күркәм булган кеше Расүлебезнең: «Иң көчле кеше – ачуы чыкканда үзен тыя белүче кеше ул», – дигән хәдисен истә тотып, башкаларны гафу итә, тормыштагы төрле хәлләрне зурга җибәрмичә үткәрә белә. Мондый кешеләр аз, әмма алар зур ихтирамга һәм сокланууга лаек.

## «ХОЛКЫМНЫ ДА КҮРКӘМ ӘЙЛӘ...»

Динебездә һәрнәрсәгә җавап бар. Беркайчан да күңелебезне төшермик. Олылар, белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп, дип әйтә торган иде. Бу очракта кимчелекләребез булу гаеп түгел, ә аларны күрергә теләмәү, танымау – гаеп, дияргә кирәк. Кешенең үз гаебен таный, күрә алуы, аларны төзәтергә теләве, алар өчен борчылуы бик мөһим адым булып тора. Динебез Исламга мөрәҗәгать итсәк, Коръән уку, һәрдаим Аллаһыны искә алу, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтү һәм күркәм әхлаклы кешеләр белән аралашу безгә бу эштә ярдәм итәчәк. Һәм, әлбәттә, Раббыбызның Расүле өйрәткән күркәм доганы истән чыгармыйк. Ул дога болай дип яңгырый: «Аллааһүммә әнтә хәссәнтә халькый фәхәссин хулүкый».

**Мәгънәсе:** «Йә Аллаһы! Сурәтемне күркәм кылган кебек, холкымны да күркәм әйлә».

Йә, Раббым, безне Үзеңнең Пәйгамбәрең салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәерле холкы белән холыкландырсаң иде. Бу дөньяда хакыйкый мөэмин-мөселманнар булып, киләчәктә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергәләшеп, мәҗлестәш булып, җәннәтләреңдә күрешүләребезне насыйп ит.

**«Хозур» редакциясе**

# ТАТАР МӘКАМЕ БЕЛӘН АЗАН ӘЙТҮ ТУРЫНДА

**Татар теленә «азан» сүзе ничек һәм каян килеп кергәнлеге турында уйлап караганыбыз бармы? «Азан» сүзе Коръәндә нибары бер тапкыр гына телгә алына, һәм җир йөзендә беренче азан әйтүче буларак, анда Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәтле 3000 ел элек яшәгән бабасы Ибраһим галәйһиссәлам хакында сүз бара:**

***«Ибраһимга*** *[галәйһиссәлам]* ***йортның урынын күрсәттек «Кешеләр арасында хаҗны*** *[фарыз буларак]* ***игълан ит, җәяү һәм һәр ерак юлдан килгән арык*** *[һәм алҗыган]* ***дөя өстендә сиңа килсеннәр».***

*«Әл-Хаҗ», 22:26-27*

Шулай итеп, җир йөзендәге беренче мөәзин Ибраһим галәйһиссәлам булганлыгы аңлашыла. Тормышының азагында борынгы бабалары корган йортның нигезен – кыйбласын табып, асылына кайткан Ибраһим галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгалә азан әйтеп, җир йөзендә таралып яшәгән адәм балаларын шушы җирләргә хаҗга чакыруын әмер итә.

Ибне Кәсир тәфсирендә хәбәр ителгәнчә, мондый боерыкны ишеткәч, Ибраһим галәйһиссәлам аптырап кала: «Шушы чүл уртасында әйткән азанымны кем, ничек ишетсен, йә Раббым?!» – ди. Моңа җавап итеп Раббыбыз: «Син азаныңны әйт, кешеләрне чакыр, чакыруыңны аларга Мин Үзем җиткерермен!» – ди. Димәк, азан – ул иң элек җан авазы! Күңел түрләреннән чыккан шөкрана белән сагыш хисләренең тышка ташып, авазга әверелгән, – сүз калыбына салынган күңел тибрәнүләре ул азан! Һәм Ибраһим галәйһиссәламнең күңеле мондый хис һәм хатирәләр белән, чыннан да, тулы иде.

Озак еллар Раббысын эзләгәннән соң, ул эзләгәнен таба. Раббыбыз аңа гасырлар буена ком астында күмелеп яткан һәм кайчандыр җәннәттән сөрелеп, җирдә яңадан кавышкан Адәм белән Хәвваның корган йортларының нигезен күрсәтә. Бу юлы ул Раббыбызга тугрылыгын раслар һәм Аңа тагы да якынаер өчен, хатыны Һаҗәр белән бәләкәй улы Исмәгыйльне, шушы комлы чүл уртасында калдырып китә, чөнки күңел күзе белән ул бу җирләрнең кайчандыр яшеллеккә күмелеп ятканын, – җәннәтне хәтерләткәнен күреп тора, димәк, – Раббыбыз аны бу очракта да ярдәмсез ташламаячагына ул катгый ышана иде. Һәм Раббысына ул болай дип дога кыла:

***«Ий Раббыбыз! Һичшиксез, мин нәселемнең бер өлешен игенсез бер үзәнлеккә, харам кылынган йортың янында урнаштырдым. Ий, Раббыбыз! Намаз укысыннар. Кешеләрдән кайберләренең күңелләрен авыштыр һәм аларны җимешләрдән ризыкландыр, – бәлки, алар шөкер итәрләр».***

*«Ибраһим», 14:37*

Һәм бөек Аллаһы Ибраһим галәйһиссәламнең мондый фидакарьлеген һәм тәвәккәллеген тиешенчә бәяли. Ибраһим хөрмәтенә комлы чүл уртасында 3000 ел бертуктаусыз агып ята торган чишмә; ә чүл астында, – Исмәгыйль нәселен 3000 елдан соң да дөньяның иң мул яшәүче кешеләреннән итәчәк кара алтын диңгезен булдыра! Ләкин Ибраһим галәйһиссәлам, чын пәйгамбәр һәм Аллаһының хакыйкый колы буларак, үзеннән соң нәсел дәвамчысы гына түгел, – ә болардан да күбрәк, – үзе башлап киткән эшенең дәвамчысы булуын тели. Һәм шуңа күрә ул Аллаһыга болай дип ялвара:

***«Ий Раббыбыз! Алар арасыннан Синең аятьләреңне укыячак, Китапны һәм Хикмәтне өйрәтәчәк һәм аларны сафландырачак бер пәйгамбәр җибәр!»***

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:129*

Раббыбыз Ибраһим галәйһиссәламнең бу догасын да тормышка ашыра. Улы Исмәгыйль нәселеннән пәйгамбәрләрнең иң ахыргысын – Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне җибәрә. Моның хакта Пәйгамбәребезнең дә: «Мин – Ибраһимның [тормышка ашкан] догасы...» – дип әйткәнлеге мәгълүм (Әхмәд бине Хәнбәл, №5/262).

Әмма Ибраһим галәйһиссәламнең бу догасы тормышка ашканчы әле күп гасырлар уза. Кайчандыр бер Аллаһыга гына гыйбадәт кылу өчен билгеләнгән Кәгъбә тирәсендә дә ялган илаһлар – потлар күренә башлый. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм заманында инде Ибраһим улы Исмәгыйль нәселеннән булган гарәпләр, дөньяга бирелеп, Кәгъбәне бөтенләй уен-көлке урынына әйләндереп бетергәннәр иде.

Шулай булгач бүген без, бабаларыбыз дин өчен чиккән җәфаларның мәгънәсен аңламыйча һәм алар диннәрен саклап калу өчен биргән корбаннарның бәясен белмичә, татар мәкаме белән азан әйтү бәйгеләре уздырырга хакыбыз бармы дигән сорау туа. Хакыбыз булса да, татар азанының, татар азанчыларының тарихларын белмичә, аларча әйткән азаннарыбыз моңсыз бер тәклидкә генә охшап калмасмы? Чөнки безнең бабаларыбыз да, Ибраһим галәйһиссәлам кебек, диннәреннән ваз кичмәс өчен, туган җирләреннән сөрелгән, утка-суга ташланган, чит җирләргә качып китәргә мәҗбүр булган. Һәм шуңа күрә милләтебезнең һәм бигрәк тә аерым шәхесләребезнең аянычлы, корбаннар һәм югалтулар тулы тарихын белмичә, – аны йөрәгебез аша уздырмыйча, татар макәмен торгызу һәм булдыру эше тәклидкә генә кайтып калачак. Мондый моңсыз азаннарга колак салучылар булса да, мәчеткә килеп намаз укырга теләүчеләр саны артмас! Сабый балаларыбызга исем кушканда да колакларына әйтелгән мондый моңсыз азаннар, аларның хәтер күзәнәкләрен кузгата алмас! Чөнки азан – ул гасырлар авазы булып яңгыраган дәгъват алымы, иманга чакыру ул!

Нәсыйхәтебезне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның 100 ел элек язып калдырган шигырь юллары белән тәмамлау урынлы булыр, бүгенге көн азанчылары өчен дә бу юлларда күркәм бер вәгазь бардыр:

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен!*

**Альберт Кадыйров**
Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчете мәхәллә әгъзасы, тәрҗемәче

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 04 (333) апрель, 2023 | Рамазан-шәүвәл, 1444



Фото: shutterstock.com

# Үзеңә теләгәнне кардәшеңә дә телә

Габдулла бине Мөсәүвирдән риваять ителгән, бер ир Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп: «Мин сиңа гыйлемнең иң гаҗәпләрен өйрәнү өчен килдем», – дигән. Расүлуллаһ: «Гыйлем башында нәрсә эшләдең?» – дип сораган. Ул кеше: «Гыйлемнең башы нәрсә?» – дигән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләне таныдыңмы?» – дигән. Бу кеше: «Әйе», – дигән. Пәйгамбәребез: «Аллаһы хакына нинди эш эшләдең?» – дип сораган. Ул: «Аллаһы теләгән нәрсәне эшләдем», – дигән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үлемне белдеңме?» – дип сораган. Ул: «Әйе», – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез: «Үлем өчен нәрсә әзерләдең?» – дип сораган. Ул: «Аллаһы теләгән нәрсәне әзерләдем», – дигән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бар, белгәннәрең белән гамәл кыл. Аннан соң килерсең һәм мин сиңа гыйлемнең иң гаҗәпләрен өйрәтермен», – дип әйткән. Ул кеше берничә елдан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына тагын килгән. Пәйгамбәребез аңа: «Кулыңны йөрәгеңә куй. Үзеңә теләмәгән нәрсәне мөселман кардәшеңә дә теләмә. Үзеңә теләгән нәрсәне мөселман кардәшеңә дә телә. Бу эш гыйлемнең иң гаҗәпләреннән булыр», – дип әйткән.

# Үлемгә әзерләнү белән мәшгуль булу

**Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үлемгә әзерләнүне бәян кылган: «Дөреслектә, үлемгә әзерләнү гыйлемнең башындадыр, үлемгә әзерләнү белән мәшгуль булу – беренчелдер».**

Габдулла бине Әл-Мөсәүвир Әл-Һәшими болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу аятьне укыды:

***«Аллаһы кемне дә булса** [туры юлга] **һидаять итәргә теләсә, Ул аның күкрәген Ислам өчен ачар. Әмма кемне дә булса** [туры] **юлдан яздырырга теләсә, аның күкрәген кысар һәм** [эченә иман нуры керә алмаслык итеп] **тарайтыр** [шул сәбәпле, Исламга чакырылган чагында] **гүяки, ул** [авырлык белән, сулый алмыйча] **күккә менә».***

*«Әл-Әнгам / Терлек», 6:125*

Моннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр кешенең күңеленә Ислам нуры керсә, күңеле киң булып ачылыр». Расүлебездән: «Моның өчен галәмәт булырмы?» – дип сораганнар. Ул: «Алдау йортыннан ерак булу һәм мәңге кала торган йортка ышану, үлем ирешкәнче үлемгә әзерләнү», – дип җавап биргән.

**«Тәнбиһүл гафилин»** китабыннан


## ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йорты «ИСЛАМ ДИНЕ НИГЕЗЛӘРЕ» («ОСНОВЫ ИСЛАМА») китабын рус телендә нәшер итте

Аллаһы Тәгалә яхшылык һәм бәрәкәт теләгән кешесенә динне аңлау бәхетен бирә. Әмма динне аңлау һәм ихластан гыйбадәт кылу гыйлемнән башка мөмкин түгел. Әлеге китап Ислам дине белән таныша башлаган һәм булган гыйлемнәрен ныгытырга теләгән кешеләр өчен әзерләнде.

«Ислам дине нигезләре» динне өйрәнүдәге төп бүлекләрне үз эченә алган, алар: гакыйдә, фикһ, сира, татарларда Ислам дине тарихы фәннәре. Башлангыч дини гыйлемне алырга һәм шулай ук үзләренең гыйлемнәрен тулыландырырга теләүчеләр өчен барлык темалар да гади һәм аңлаешлы телдә бирелгән.




**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**
**Кибет:** Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт.
Тел.: +7 960 072-74-63;
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09;
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru

РЕКЛАМА 12+

# ГОМЕРЛЕК ЯР САЙЛАУ

**Динебез никахны җанны тынычландыру чарасы итеп күрә. Ул – ир белән хатынның бер-берсен яратып, ихласлык белән бердәм тормыш коруыдыр. Максат – бәхетле һәм үзара мәхәббәт, мәрхәмәт белән тулган чын мөселман гаиләсе төзү, иманлы балалар тәрбияләп үстерү.**

Моңа ничек ирешергә? Бик еш бирелә торган һәм бик күп гаиләләргә кагылышлы сорау бу. Ничек хаталанмаска? Үзеңә тиң яр табуда нинди таләпләрдән чыгып эш итәргә соң?

Ана карынындагы сабыйга 121 көннән җан керә. Аңа, Аллаһы Тәгалә әмере белән, дүрт кәлимә языла: баланың гомере, гамәле, ризыгы, бәхете-бәхетсезлеге. «Тәкъдиреңә нәрсә язылган, шуны күрәсең», дигән халык сүзе дә шуннан килә. Әмма язылганнарга игелекле гамәлләр һәм дога да тәэсир итә. Аны, бигрәк тә, Кадер кичендә теләгән теләкләр үзгәртергә мөмкин. Намаз артыннан, икенде белән ахшам намазы арасында Коръән укып, теләгеңне Аллаһы Тәгаләдән чын ихлас күңел белән сорау хуплана. Халыкта «кәсеби-насыйби» дигән әйтем дә бар. Аны да истән чыгармаска кирәк. Иң элек, син үзеңә ни теләвеңне, нәрсә сорарга кирәклеген ачык белергә тиешсең. Сиңа, синең холкыңа, нәселеңә ниндирәк кеше кулай булуын ачыкларга кирәк. Бу бик мөһим. Үткән чор кешеләре кебек, «чалбар кисә, шул ир була», дип кенә тормышка чыкмыйлар. Бу ялгыш фикерне бүгенгеләр, берүк, кабатлый күрмәсеннәр иде.

Ислам дине буенча, кыз бала үзенең гаилә корырга әзерлеген аңлагач та, әти-әнисенә, якын ир туганына шуны ачыктан-ачык белдерә ала. Моның һич ояты юк.

«Әти (яки абый)! Минем тормышка чыгып, үз гаиләмне булдырасым, ана буласым килә», – дип әйтүнең гаебе юк. Үз оясын кору киңәшләшеп эшләнә торган бик җаваплы эш. Нәрсәләргә игътибар итәргә?

Беренчедән, түбәндәге таләпләрне истә тотарга кирәк.

Кавышырга ниятләгән парларның диннәре туры килергә тиеш. Ягъни, егетнең дә, кызның да бер диндә булуы шарт. Икесенең диндәге торышы бер дәрәҗәдә булса, никах тотрыклы була. Берсе – намазда, ә икенчесе әлегә намазын торгызмаган булса, тормышта авырга туры киләчәк. Шуңа да намаз укуга кагылышлы таләпне никахка кадәр үк хәл итү хәерле. Никахтан соң, «вакыты җиткәч басармын әле» дип, тартып-сузып йөрергә урын калмасын.

Нәсел-нәсәбен белү бик тиеш. Юкка гына Аллаһы Тәгалә моны төп шартларның берсе итеп күрсәтмәгән. Халык арасында да «әнисенә карап кызын коч» дигән әйтем бар. Әнисе хатын-кыз эшен белмәсә, бу вазифаларның барысы да «син – гаилә башлыгы» дип, ир иңенә өелсә, Аллаһы сакласын, бу нәселдән еррак торуың хәерле. Киресенчә, әтиләре диванда ятып, әниләре авыр сумкалар күтәреп кайтса да, кыз кеше башын азрак эшләтергә, булачак иренең дә әтисе гадәтен дәвам итү куркынычы барлыгын уйларга тиеш. Тормышны икең бергә җигелеп тартканда болар вак нәрсәләр түгел.

Берсен-берсе сайлаган егет белән кызның белем дәрәҗәләре бер тирә булуы да исәпкә алынырга тиеш. Бу да мөһим шарт. Берсе югары белем алган, икенчесе урта мәктәп белән генә тукталып калган булса, сөйләшер уртак темалары, кызыксындырган өлкәләре, ай-һай, булырмы? Бу очракта хатын-кыз «муен» түгел, бары тик өй җыештыручы гына булып кала. Хатын ирдән калышмаска тиеш. Шул вакытта гына ир үз хатынын тиң күрәчәк. Әгәр ир – гади һөнәр иясе, хатыны исә шактый карьерага ирешеп, бүгенгечә әйтсәк, уңышлы, дәрәҗәле урын биләсә, бу очракта да ирнең мәхәббәте озакка сузылмас. Чөнки ирләрне Аллаһы Тәгалә шулай яраткан инде. Ир кешенең һәрвакыт үзен гаилә башлыгы, хатыннан өстенрәк итеп күрсәтәсе килә. Әмма бит аяк «юрганга карап сузыла». Бу хакта миңа каенатам Габделхәмит Аппаков (1900-1968) бәйнә-бәйнә аңлатыр иде. Никадәрле дә хаклы булган аның тормыш дәресләре.

Егетнең дә, кызның да тормыш дәрәҗәләре бер чама булуы хәерле. Әгәр егет баерак булып, хатынын киендерә алса, тормышлары матур гына бара кебек. Әмма бер вакыт ир дигәне «синең миңа чыкканда нәрсәң бар иде соң» дисә, хатын күңеленә гомерлек яра салына дигән сүз. Хатынының сабыр итүе, нервысы бәрабәренә ир «патша» булып яшиячәк. Әгәр хатын бай булып, ире фәкыйрь булса, бу инде көн саен концерт диярлек. Хатын үзен «баш» итеп куячак, ир исә йомышчы хәлендә. Кайнар мәхәббәт тиз сүнәчәк, күпме генә үгетләмә, татуландырырга тырышма, хәлле тормышта үскән хатынның «минмин»лек чире калачак.

Менә шуларны күз алдында тотып, алдын-артын нык уйлап сайлаганда да таманга гына туры килә әле ул бер түбә астында ир-хатын, бербөтен гаилә булып яшәү. Боларга өстәп, кызларга бик тә чиста, пөхтә, тыйнак йөрсәләр, егетләр (өйләнү нияте белән йөрүчеләре) күз төшерми калмый. Егетләрнең бер генә дә «айт-тайт» булып, кендек күрсәтеп йөрүче кызларга өйләнәсе килми аларның. Өйләнү ниятенә кергәч, мәчеткә йөрүче, тәртипле, әдәп-инсафлы кызлар арасыннан яр сайларга тырышалар. Тагын шунысын онытмагыз, җитди, акыллы, тормышын матур итеп төзергә хыялланган егет төнге клубларда үзенә яр эзләми.

Аллаһы Тәгалә Адәмне баш итеп ярата. Шулай булса да, җәннәттә аңа, күрәсең, күңелсез булган. Ел буена да ул елмаймаган. Аннан соң Адәмнең сул як кабыргасыннан Анабыз Һава яратылган. Адәм шунда ук елмая башлый. Бу бит безгә гыйбрәт. Димәк, кешеләр бүген монда, иртәгә тегендә зина кылып йөрергә тиеш түгел. Киресенчә, бер гаилә булып, никахланышып яшәргә тиеш.

Гаилә ул кечкенә генә бер дәүләт. Аның үз кануннары, үз вазифалары, таләпләре шактый. Дөньяви зур дәүләт строе гаилә дигән шул кечкенә дәүләтләрдән оеша. Никах белән гаиләне ныгытабыз икән, никахларыбыз тотрыклы, озын гомерле икән, димәк, дәүләтебез дә тыныч, иманлы, бай булачак, иншәАллаһ. Әхлакый тәрбияле, рухи яктан бай, гыйлемле булып яшәүгә ни җитә?!

**Сәйдә абыстай Аппакованың**
«Тузмас бүләк» китабыннан

# Сөннәтче бабай


Фото: shutterstock.com

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Шул тынлыкта гомер үтеп килгәндә, шул тынлыкның очы, төбе күрелмәгәндә, бер көнне иртә берлән хәзрәт йоклап ятканда, Сөннәтче бабай ишекне кагып хәзрәтне уятты. Калтыраган, каушаган тавыш берлән, бабай:

– Хәзрәт, хәзрәт, карчык авырып китте. Ясин укырга рәхим итмәссеңме? – диде.

Хәзрәт, Сөннәтче бабайны юатып: «Иншалла, кичәр, суык тигәндер», – дисә дә, күңеленнән, чыннан да, куркып китте. Тиз генә тәһарәтләнеп, бабай берлән китте. Гөлйөзем әбине яктан-якка бәрелә-сугыла торган, «Алла, алла!» дип ыңгыраша торган рәвештә тапты, бик ихлас берлән Ясинны укыды; бик озын иттереп дога кылды. Сөннәтче бабайны тагы юатып, чыгып китте.

Кайтып җитү берлән, самовар берлән көтеп тора торган остазбикәгә хәлне сөйләгәч, ул да курыкты. Ул, чәене эчәр-эчмәс, хаҗ шәрифтән килгән, балалар авызландырырга тотыла торган хөрмәне алып, кечкенә генә савытка пешкән каймак салып, хәл белергә китте. Күрше Гадилә әби берлән бергә самовар куеп, мәтрүшкә дә эчертте. Салават шәриф укып, хөрмәдән дә авыз иттерде. Үзе дә дога кылып өшкереп, Гөлйөзем әбине рәтләп яткырды. Өйлә тәһарәте берлән хәзрәт тарелкага зәгъфран берлән аяте шифа да язып җибәрде. Күрше хатыннары берлән абыстай, Гөлйөзем әбине тәһарәтләндереп, аны да эчерде.

Ләкин Гөлйөзем әби җиңеләймәде. Ул икенде намазыны тәяммем (су булмаганда кулларны туфракка сугып тәһарәт алу – ред.) берлән генә, хәзрәтнең рөхсәте вә фәтвасы (нинди дә булса бер эшне эшләү дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирүе – ред.) берлән утырып кына укый алса да, ахшам намазын бөтенләй кыла алмады. Ул, башын күтәрә алмаенча, кай вакыт иссез, хәлсез булып киткәнгә, Сөннәтче бабай, башына җыелган бозык каннарны чыгарыр өчен, кан алмакчы да булды. Ләкин шундый зур эшне эшләүдә көне, ае тугъры килмәенчә, гөнаһлы булмас өчен, ахшамнан соң хәзрәтне күреп сорады. Җәйнең эссе ае булганга, хәзрәт баштан ук: «Ярамый, канның сыекланган чагы», – дип, рөхсәт бирмәде. Бабай бик йөдәткәнгә: «Тагы бер-бер ривайәт булмасмы, китапта бер-бер кыйль вә каль (имеш-мимеш, төрлечә юраулар – ред.) булмасмы, яравына ривайәт юкмы», – дип, бик озак китап караса да, алдыруның файдасына һичбер дәлил таба алмады.

Хәзрәт ястү намазына тәһарәт алып бетерергә өлгермәде, Сөннәтче бабай килеп, егълаган тавыш берлән:

– Хәзрәт, бик авырайды, телдән калды, – диде.

Хәзрәт, аның авыраюында, телдән калуында үзен гаепле итеп хис иткән кеби булганга, тиз-тиз китеп киенде. Абыстай да, тагы бераз зәмзәм, кипкән инҗир, имбир алып, аның артыннан калмады.

Ясинны хәзрәт никадәр ихлас берлән укыса да, абыстай да никадәр ихлас берлән шул дарулары берлән даруларга тырышса да, Гөлйөзем әби берсен дә каба алмады. Ул көчкә-көчкә генә бер-ике тамчы зәмзәм суына башка берсен дә йота алмады. Күршенең Мәрфуга әби, Гадилә абигә төнләргә калдырып, хәзрәт берлән абыстай кайтып киттеләр.

Ләкин иртә берлән таң атар-атмас Сөннәтче бабай килеп, хәзрәтләрне уятып:

– Карчык дөньяны куйды! – диде.

Сөннәтче бабай шул сүзне әйткәндә һәм дә иртә берлән мәсҗедтә, намаздан соң, халыкка: «Җәмәгать, карчык дөньяны ташлаган иде, кабер казырга ярдәм итешсәңез лә», – дигәндә дә тавышында, кылынышында әллә нинди кайгылылык беленмәде. Кылынышларында хәтта бер бәйрәмгә хәзерләнү кеби әллә нәрсәдер сизелде.

Бөтен авыл кабер казырга китте. Бөтен авыл хатыны Гөлйөзем әбинең өстенә җыелдылар. Иртәге чәйне эчкәч үк абыстай да китап сөйләргә китте. Бик озын иттереп, үлем хакында, кабер газабы хакында, оҗмах, тәмуг хакында китап сөйләгәннең соңында, Гөлйөзем әбигә үзе кәфен кисте. Карт мөәззин хатыны, су коеп, үзе Гөлйөзем әбине юды. Хаҗ җиреннән килгән Мәрьям аңа чәчен (хөрмә агачының мунчаласын) зәмзәм суына үзе манып биреп, кәфенне тектерде.

Җеназа да өлгерде. Бөтен авылның картлары тәһлилгә җыелды. Гөлйөзем әбинең әллә кайчан хәзерләп куелган унике тастымаллары тәһлилгә өләшелде; кәфенне бәйләргә куелган кызыл башлы өч сөлгесе хәзрәтләргә бирелде. Сандыгыннан чыккан илле баш берәр тиен ярымлыклар, егерме биш баш өч тиенлекләр җыелганнарга таратылды. Мәсҗед янына җыелган дүрт-биш йөз кеше җеназасын укып озатты. Җомгага кадәр күмелеп бетеп, хәзрәтләр Сөннәтче бабайның өендә актык фатиханы да кылдылар. Җомга намазыннан соң хәзрәт бөтен мәсҗедтән һәүл (мәет күмелгән көнне кичен укыла торган намаз – ред.) намазын да укытты. Сөннәтче бабай барысында да бик нык кылынып, үзенең кайгылылыгын артык сиздермәде, йә сизенмәде. Җомгадан чыгуга ул хәзрәтләр берлән ашка да барды. Анда да шактый ашады, эчте.

Менә өенә кайтып китте. Әллә никадәр күрше карчыклары берлән тулган канәфер мае исле өй аны бердән башына суккан кеби кабул итте. Ул, ишекне ачып керү берлән, шул канәфер мае исе борынга керү берлән, карчыгының, Гөлйөземенең, шул, үзе берлән илле, алтмыш, җитмеш ел яшәгән карчыгының юклыгын, аның тагы бер мәртәбә кайтмый торган җиргә киткәнлеген, аның үлгәнен белде...

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Гаяз Исхакый**

## ДҮШӘМБЕ

**07.00** «Минбар»
**07.25** «Хәерле сәгатьтә»
**08.20, 17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә»
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев
**09.35, 18.25** «Фикер»
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары»
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары»
**11.00, 19.55** «Дин турында»
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр»
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Чудеса сотворения»
**12.20, 21.15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**12.35, 21.30** «Онлайн медресе»
**13.10, 22.05** «Знамения Корана в свете современной науки»
**13.25, 22.20** «Узнаем у имама»
**14.10** «Разговоры о важном»
**14.15, 23.05** «Алифба»
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис»
**15.00, 23.25** Документальные фильмы
**15.35** «Тайна»
**15.55** «Халяль-лайфстайл»
**16.15** «Рухуль Байан»
**16.20** «Ислам сегодня»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## СИШӘМБЕ

**07.00** «Минбар»
**07.35** «Хәерле сәгатьтә»
**08.30, 17.25** «Җан авазы»
**08.45, 17.40** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**09.00, 17.50** «Рисәлә»
**09.15, 18.05** «Сабыйлар остаханәсе»
**09.35, 18.25** «Рухел Бәйан»
**09.45, 18.35** «Татарлар тарихы»
**10.30, 19.25** «Тәмле булсын»
**10.50, 19.45** «Имамнан сорыйк»
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Азбука Ислама»
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе»
**13.05, 22.00** «Дети в саду пророчества»
**13.25, 22.20** «40 хадисов – 40 толкований»
**14.00, 22.55** «Узнаем у имама»
**14.45, 23.40** «Халид бин Валид»
**15.40** «Познай свою религию»
**16.00** «Ислам сегодня»
**16.40, 00.35** «Поучительные истории» (до 5 минут)
**16.45, 00.40** «Хафтияк Шариф»
**17.00** «Мәслихәт»
**20.35** «Гыйбрәтле хикәяләр»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## ЧӘРШӘМБЕ

**07.00** «Минбар»
**07.25** «Хәерле сәгатьтә»
**08.20, 17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә»
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев
**09.35, 18.25** «Бәрәкәтле гаилә»
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары»
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары»
**11.00, 19.55** «Дин турында»
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр»
**11.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Вера в предопределение»
**12.15, 21.10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе»
**12.55** «40 хадисов – 40 толкований»
**13.30, 22.05** «Узнаем у имама»
**14.20, 21.50** «Знамения Корана в свете современной науки»
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис»
**15.00, 23.20** Документальные фильмы (природа)
**15.35, 23.55** «Тайна» (Архив. Ислам ру)
**15.55, 00.15** «Голос разума»
**16.30, 00.50** «Рухуль Байан»
**16.35** «История ислама в России»
**20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен)
**22.55** «Есть вопрос – есть хадис»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## ПӘНҖЕШӘМБЕ

**07.00** «Минбар»
**07.25** «Хәерле сәгатьтә»
**08.20, 17.00, 17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә»
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев
**09.35, 18.25** «Фикер»
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары»
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары»
**11.00, 19.55** «Дин турында»
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр»
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Чудеса сотворения»
**12.20, 21.15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**12.35, 21.30** «Онлайн медресе»
**13.10, 22.05** «Знамения Корана в свете современной науки»
**13.25, 22.20** «Узнаем у имама»
**14.10** «Разговоры о важном»
**14.15, 23.05** «Алифба»
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис»
**15.00, 23.25** Документальные фильмы
**15.35** «Тайна»
**15.55** «Халяль-лайфстайл»
**16.15** «Рухуль Байан»
**16.20** «Ислам сегодня»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## ҖОМГА

**07.00** «Минбар»
**07.35** «Хәерле сәгатьтә»
**08.30, 17.25** «Җан авазы»
**08.45, 17.40** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**09.00, 17.50** «Рисәлә»
**09.15, 18.05** «Сабыйлар остаханәсе»
**09.35, 18.25** «Рухел Бәйан»
**09.45, 18.35** «Татарлар тарихы»
**10.30, 19.25** «Тәмле булсын»
**10.50, 19.45** «Имамнан сорыйк»
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Азбука Ислама»
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе»
**13.05, 22.00** «Дети в саду пророчества»
**13.25, 22.20** «40 хадисов – 40 толкований»
**14.00, 22.55** «Узнаем у имама»
**14.45, 23.40** «Халид бин Валид»
**15.40** «Познай свою религию»
**16.00** «Ислам сегодня»
**16.40, 00.35** «Поучительные истории» (до 5 минут)
**16.45, 00.20** «Хафтияк Шариф»
**17.00** «Мәслихәт»
**20.35** «Гыйбрәтле хикәяләр»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## ШИМБӘ

**07.00** «Минбар»
**07.25** «Хәерле сәгатьтә»
**08.20, 17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә»
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев
**09.35, 18.25** «Бәрәкәтле гаилә»
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары»
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары»
**11.00, 19.55** «Дин турында»
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр»
**11.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Вера в предопределение»
**12.15, 21.10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе»
**12.55** «40 хадисов – 40 толкований»
**13.30, 22.05** «Узнаем у имама»
**14.20, 21.50** «Знамения Корана в свете современной науки»
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис»
**15.00, 23.20** Документальные фильмы (природа)
**15.35, 23.55** «Тайна» (Архив. Ислам ру)
**15.55, 00.15** «Голос разума»
**16.30, 00.50** «Рухуль Байан»
**16.35** «История ислама в России»
**20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен)
**22.55** «Есть вопрос – есть хадис»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## ЯКШӘМБЕ

**07.00** «Минбар»
**07.35, 17.25** «Шифа»
**08.10, 18.00** «Фикер»
**09.00, 18.50** «Дин турында»
**09.35, 19.20** «Мәслихәт»
**10.00, 19.45** «Әхлак сабаклары»
**10.10, 19.55** «Балам-багалмам»
**10.35** «Имамнан сорыйк»
**11.25** Фильм: «Шиһабетдин Мәрҗани»
**12.00** Азан
**12.05** «Онлайн медресе»
**12.30, 21.25** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**12.45, 21.40** «Минбар. Истории»
**13.15, 22.10** «Ислам сегодня»
**13.55, 22.50** «Познай свою религию»
**14.15, 23.10** «Узнаем у имама»
**15.00, 23.55** Документальные фильмы
**15.35, 00.30** «Медицина Пророка»
**16.00** Короткометражный фильм
**16.25** «40 хадисов – 40 толкований»
**17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**20.20** Фильм: «ТР МДН – 30 ел»
**20.50** «Мөнәҗәттә халкым моңы»
**21.00** «Онлайн медресе»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод


# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДННең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДННең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Юлдашева А. И., Ситдикова Г.Р.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2588.
График буенча – 24 нче апрель 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 168,90 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы апрель көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## МАЙ 2023 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Дүш | 00:45 | 02:31 | 04:01 | 11:40 | 12:00 | 16:52 | 19:21 | 21:45 |
| 02 | Сиш | 00:37 | 02:29 | 03:59 | 11:40 | 12:00 | 16:53 | 19:23 | 21:49 |
| 03 | Чәрш | 00:28 | 02:26 | 03:56 | 11:40 | 12:00 | 16:54 | 19:25 | 21:53 |
| 04 | Пәнҗ | 00:17 | 02:24 | 03:54 | 11:40 | 12:00 | 16:55 | 19:27 | 21:58 |
| 05 | Җом | 00:01 | 02:22 | 03:52 | 11:40 | 12:00 | 16:57 | 19:29 | 20:59 |
| 06 | Шим | 01:50 | 02:20 | 03:50 | 11:40 | 12:00 | 16:58 | 19:31 | 21:01 |
| 07 | Якш | 01:48 | 02:18 | 03:48 | 11:40 | 12:00 | 16:59 | 19:33 | 21:03 |
| 08 | Дүш | 01:46 | 02:16 | 03:46 | 11:40 | 12:00 | 17:00 | 19:35 | 21:05 |
| 09 | Сиш | 01:44 | 02:14 | 03:44 | 11:39 | 12:00 | 17:01 | 19:37 | 21:07 |
| 10 | Чәрш | 01:42 | 02:12 | 03:42 | 11:39 | 12:00 | 17:02 | 19:38 | 21:08 |
| 11 | Пәнҗ | 01:40 | 02:10 | 03:40 | 11:39 | 12:00 | 17:03 | 19:40 | 21:10 |
| 12 | Җом | 01:38 | 02:08 | 03:38 | 11:39 | 12:00 | 17:05 | 19:42 | 21:12 |
| 13 | Шим | 01:36 | 02:06 | 03:36 | 11:39 | 12:00 | 17:06 | 19:44 | 21:14 |
| 14 | Якш | 01:34 | 02:04 | 03:34 | 11:39 | 12:00 | 17:07 | 19:46 | 21:16 |
| 15 | Дүш | 01:32 | 02:02 | 03:32 | 11:39 | 12:00 | 17:08 | 19:48 | 21:18 |
| 16 | Сиш | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 11:39 | 12:00 | 17:09 | 19:50 | 21:20 |
| 17 | Чәрш | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 11:39 | 12:00 | 17:10 | 19:52 | 21:22 |
| 18 | Пәнҗ | 01:27 | 01:57 | 03:27 | 11:39 | 12:00 | 17:11 | 19:53 | 21:23 |
| 19 | Җом | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 11:39 | 12:00 | 17:12 | 19:55 | 21:25 |
| 20 | Шим | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 11:40 | 12:00 | 17:13 | 19:57 | 21:27 |
| 21 | Якш | 01:22 | 01:52 | 03:22 | 11:40 | 12:00 | 17:14 | 19:59 | 21:29 |
| 22 | Дүш | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 11:40 | 12:00 | 17:15 | 20:00 | 21:30 |
| 23 | Сиш | 01:19 | 01:49 | 03:19 | 11:40 | 12:00 | 17:16 | 20:02 | 21:32 |
| 24 | Чәрш | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 11:40 | 12:00 | 17:17 | 20:04 | 21:34 |
| 25 | Пәнҗ | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 11:40 | 12:00 | 17:18 | 20:05 | 21:35 |
| 26 | Җом | 01:14 | 01:44 | 03:14 | 11:40 | 12:00 | 17:18 | 20:07 | 21:37 |
| 27 | Шим | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 11:40 | 12:00 | 17:19 | 20:08 | 21:38 |
| 28 | Якш | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 11:40 | 12:00 | 17:20 | 20:10 | 21:40 |
| 29 | Дүш | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 11:40 | 12:00 | 17:21 | 20:11 | 21:41 |
| 30 | Сиш | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 11:41 | 12:00 | 17:22 | 20:13 | 21:43 |
| 31 | Чәрш | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 11:41 | 12:00 | 17:23 | 20:14 | 21:44 |